**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Югары Чура авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2020 ел** **№2**

**«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 27 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районының Югары Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2020 елның 27 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районының Югары Чүра авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2020 елның 30 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районының Югары Чүра авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының оченче этабын билгеләргә.

4 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Вахитов урамы, Пионер авылы-Чура урамындагы юлларга вак таш түшәү (сатып алу, күчереп йөртү, вак таш түшәү); проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары Чура авылының Вахитов урамында вак таш җәелгән юлларын ремонтлау;

-Югары Чура авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру махсус җайланмаларны сатып алу, урам яктырткычлары, яктырткычлар урнаштыру;

-Югары Чура авылынын Мәктәп урамына юл билгеләре алу

- Село-Чура авылына насослар сатып алу;

-Село-Чура авылы чишмәсен төзекләндерү; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-чишмә янындагы мәйданчыкны тигезләү;

-Югары Чура авылынында Вахитов урамына  автомобиль күперен төзү; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Село-Чура авылында Вахитов урамындагы җәяүле күперне ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-төзекләндерү  һәм буа төзү  Село-Чура авылы проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-Село-Чура авылындагы юлларны кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү;

- Село-Чура авылы урамнарында корыган агачларны һәм куакларны кисү,  санитар эшкәртү; махсус техника табу; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-Село-Чура авылында видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Югары Чура авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы: И. Н.Алексеев